КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 апрель г.Казань № 519

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 41 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 26 нчы; 2021 ел, 28 гыйнвар, 31 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт

хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтага, «3» астөшермәсендәге «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин